Белем коне (1 сентябрь, Беренче кынгырау) — дәүләт бәйрәме, һәр елны 1 сентябрьдә билгеләп vтелә. Белем конендә мәктәпләрдә тантаналы чаралар, сыйныф сәгатьләре, белем, тынычлык, иминлек, батырлык темаларын яктырткан дәресләр уза. Быел да Мордовиянен һәрбер белем учагында, шул исәптән, татар мәктәпләрендә 1 сентябрьне бергәләп бәйрәм иттек.

1 сентябрь — Белем доньясына яна сәяхәт башы, бу беренче кынгырау һәм дулкынлану, чәчәкләр һәм ак бантларнын кvплеге һәм, әлбәттә

традицион тынычлык дәресләре. Мәктәп бусагасын беренче тапкыр атлап кергәннәр очен бу аеруча да котеп алынган кон булса, олкәннәр очен дә бердәй кадерле, якын ул. Балачак, vсмерчакнын ин якты хатирәләре мәктәп еллары белән бәйле. Мәктәптәге белемнәр сезнен киләчәктә Мордовия һәм ботен Россия файдасына ирешкән унышларыгыз очен

нигез булачак. Сез рәхәтләнеп укысын очен Мордовия мәктәпләр, коллиятләр һәм техникумнар биналары ремонтланды, сыйныфлар, лабораторияләр, спорт заллары һәм китапханәләр янартылды һәм янартыла. Мәктәптә укучыларнын киләчәге башлана,

һәм безнен уртак бурыч – аны якты һәм унышлы итv. Барлык укучыларга белем нигезләрен тырышып, кызыксынып vзләштерvләрен телибез. Ин матур кеше — белемгә омтылган кеше. Шуна кvрә һәрчак белемле булыйк, белемгә омтылыйк!
Яна уку елы һәркайсыбызга бары тик яхшы хис-кичерешләр, зур унышлар һәм шатлык алып килсен, ижади ачышлар һәм жинvләр елы булсын, хыялларыбыз тормышка ашсын.
Белем бәйрәме белән! Хәерле сәгатьтә!